Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге
Тогашево торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

28 ноябрь, 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Тогашево торак пунктында 2021 елның 28 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 82 (сиксән биш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 46 (кырык алты).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 43 (кырык өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 3 (өч).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2022 елда Тогашево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, 1 төркем инвалидларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Колай авыл җирлеге башлыгы Поповская Н.В. Поповская